**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

2025 елның «24» ноябреннән | № 252

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең түләүле хезмәтләр күрсәтүгә бәяләрне раслау турында» 2025 елның 23 гыйнварындагы 16 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль бюджет учреждениеләре тарафыннан түләүле һәм керем китерә торган башка хезмәтләр күрсәтү турындагы нигезләмәләрне раслау хакында» 2023 елның 29 декабрендәге 40-325 номерлы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карары нигезендә, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр күрсәтүне тәртипкә салу максатларында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең түләүле хезмәтләр күрсәтүгә бәяләрне раслау турында» 2025 елның 23 гыйнварындагы 16 номерлы карарына (2025 елның 03 сентябрендәге 178 номерлы карардагы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенең түләүле

хезмәтләр күрсәтүгә бәяләр прейскуранты» исемле таблицасына түбәндәге эчтәлектәге 29, 30, 31 пунктлар өстәргә:

«

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 29 | Бассейнда тренер җитәкчелегендә балаларны савыктыру буенча төркемләп йөзү дәресләре (*әлеге спорт төренә ташлама бирелми) | 1 кешегә | - | 1200,00 |
| 30 | Тренер җитәкчелегендә балалар өчен төркемләп футбол (мини-футбол) буенча дәресләр (*әлеге спорт төренә ташлама бирелми) | 1 кешегә | - | 1200,00 |
| 31 | Футбол манежының спорт залын арендалау | Бер сәгатькә | 1200,00 | |

».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https:/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.Л.Еронтьевка йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов